КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 24 февраль г.Казань № 159

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 23 апрель, 332 нче карары белән расланган Акцияләрнең (өлешләрнең) 100 проценты Татарстан Республикасыныкы булган юридик затларга әлеге затлар милкендә булган капиталь төзелеш объектларына һәм (яки) алар тарафыннан күчемсез мөлкәт объектларын сатып алуга капитал салуларны гамәлгә ашыруга, алга таба мондый юридик затларның устав капиталларын Россия Федерациясе законнары нигезендә арттыру белән Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Акцияләрнең (өлешләрнең) 100 проценты Татарстан Республикасыныкы булган юридик затларга әлеге затлар милкендә булган капиталь төзелеш объектларына һәм (яки) алар тарафыннан күчемсез мөлкәт объектларын сатып алуга капитал салуларны гамәлгә ашыруга, алга таба мондый юридик затларның устав капиталларын Россия Федерациясе законнары нигезендә арттыру белән Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында" 2019 ел, 23 апрель, 332 нче карары белән расланган Акцияләрнең (өлешләрнең) 100 проценты Татарстан Республикасыныкы булган юридик затларга әлеге затлар милкендә булган капиталь төзелеш объектларына һәм (яки) алар тарафыннан күчемсез мөлкәт объектларын сатып алуга капитал салуларны гамәлгә ашыруга, алга таба мондый юридик затларның устав капиталларын Россия Федерациясе законнары нигезендә арттыру

белән Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

түбәндәге эчтәлекле $8^1$ пункт өстәргә:

«$8^1$. Юридик зат финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнар турында хисап биргәннән соң Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын алучы әлеге Тәртипнең 8 пункты нигезендә 10 эш көне дәвамында Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына капиталь төзелеш объектларына капитал салуларны гамәлгә ашыруга фактта башкарылган эшләрне дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсен алган проект (смета) документациясенә туры килүенә тикшерү өчен түбәндәге документларны җибәрә:

объектларны төзү, модернизацияләү һәм (яисә) реконструкцияләү эшләрен башкаруга подряд шартнамәләренең күчермәләрен;

эшләрне кабул итү актларының күчермәләрен;

КС-3 формасы буенча сәнәгать (индустриаль) паркын төзүгә һәм (яисә) үстерүгә башкарылган эшләр бәясе турындагы белешмәләр күчермәләре;

КС-2 формасы буенча сәнәгать (индустриаль) паркын төзүгә һәм (яисә) үстерүгә башкарылган эшләрне кабул итү турында актларның күчермәләре.»;

түбәндәге эчтәлекле $8^2$ пункт өстәргә:

«$8^2$. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы әлеге Тәртипнең $8^1$ пункты нигезендә Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын алучы тарафыннан тапшырылган документларны 10 эш көне эчендә тикшерә һәм өч эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын алучыга тапшырылган документларның дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсен алган проект (смета) документациясенә туры килүе яисә туры килмәве турында бәяләмә җибәрә».

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин